Мошенниклар vз корбаннарынын виртуаль образларын куллана башлаганнар.
Яна схема сценарие буенча, кешеләр vзләренен смартфоннарында бу образларны vзләре тудыра. Мошенниклар кешегә телефоннан яки мессенджердан шалтыраталар һәм анын акчаларын кемдер урларга омтыла дип раслыйлар.

Акчаны куркынычсызландыру очен, ашыгыч рәвештә телефонда янәсе Үзәк Банкнын кушымтасын урнаштырырга кvндерәләр. Бу кушымта исемнәренен вариантлары торле булырга момкин. Кушымта куелганда, мошенниклар жайланмадан файдалануны тыя. Ә кушымтаны урнаштырганнан сон эшләтеп жибәрергә, vз картасын телефонга кертергә һәм «регулятор кушымтасында авторизация» сылтавы белән банктан раслау кодын кертергә дә сорыйлар.
Чынлыкта мошенниклар ачыкларга сораган кушымта корбаннын банк картасынын виртуаль образын тудыра. Контактсыз технологиягә ярдәм итvче банкоматларда акча алу очен алар аны vз телефоннарында читтән торып кулланалар. Ягъни, чит кешенен банк картасы урынына алар vз смартфонын банкоматка куялар.
Нәрсәне истә тоту моһим: ят кешеләр vтенече буенча бернинди кушымталар яки программалар йокләмәгез һәм кушымталарны, шул исәптән банк кушымталарын да, кемнен дә булса таләбе буенча кулланмагыз. Һәм әлбәттә, чит кешеләргә шәхси һәм финанс мәгълvматларын, алар нинди генә сылтау белән белергә тырышсалар да, хәбәр итәргә ярамый. Әгәр акчанын саклануына шикләнәсез икән - Банкнын рәсми сайтыннан яки картанын икенче ягыннан кулдан номер жыеп, vз банкыгызга шалтыратыгыз.
Яна схема буенча картагызнын виртуаль образларын булдырмау очен сак булыгыз һәм монын турында якыннарыгызга, бигрәк тә олкәннәргә сойләгез.